**Татарстан Республикасы**
**Лениногорск муниципаль районы**
**Кирлегәч авыл җирлеге**
**Кирлегәч авылында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2021 елның 20 ноябре № 1

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кирлегәч авыл җирлегенең Кирлегәч авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 20 ноябрендә 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль Кирлегәч авыл җирлегенең Кирлегәч авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, студентлардан тыш, 300 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Кирлегәч авылында Ленин, Кустарная урамнары буенча вак таш җәелгән юлларны ремонтлау буенча эш (вак таш җәю, смета нигезендә килешү буенча түләү).

«ӘЙЕ» «ЮК».

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 325 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 167 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар бертавыштан «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирделәр.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кирлегәч авыл җирлегенең Кирлегәч авылында гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кирлегәч авыл җирлеге составына керүче Кирлегәч торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль Кирлегәч авыл җирлегенең Кирлегәч авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, студентлардан тыш, 300 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме соравы буенча:

җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Кирлегәч авылында Ленин, Кустарная урамнары буенча вак таш җәелгән юлларны ремонтлау буенча эш (вак таш җәю, смета нигезендә килешү буенча түләү) карарны кабул ителгән, дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Кирлегәч авылы, авыл мәдәният йорты - Советская 33А адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Кирлегәч авыл җирлеге башлыгы: С.Р.Сәлахова